Республика Татарстан
СОВЕТ
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**2021нче ел 10 декабрь** **№ 19**

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
Ләке авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына
бюджеты турында» карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

**1 Статья**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 елга бюджетынын төп характеристикасын расларга:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 3313,7 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3 313,7 мең сум.;

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024 елга бюджетынын төп характеристикасын расларга:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2023 елга фаразланган кеременең гомуми күләме 3 390,9 мең сум һәм 2024 елга 469,63 мең сум күләмендә.;

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетының 2023 елга гомуми чыгымнары күләме 3 390,9 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 90,0 мең сум күләмендә, һәм 2024 елга 3 469,6 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-180,00 мең сум күләмендә.;

3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2023 елга 0,0 мең сумга һәм 2024 елга 0,0 мең сумга.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең 2022 нче елга һәм 2023, 2024 нче еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**2 Статья**

1. 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2024 нче елның 1 нче гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең муниципаль гарантияләр буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2025 нче елның 1 нче гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең муниципаль гарантияләр буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**3 Статья**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетында 2022 нче елга һәм 2023, 2024 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга, 2 нче кушымта.

**4 Статья**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетының 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына керемнәрен бүлү нормативларын расларга, әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә, карар кабул ителде.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген шушы карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетының 2022 елга халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2023 елга-0,0 мең сум, 2024 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**5 Статья**

1. Ләке авыл җирлеге бюджетыннан 2022 елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 1 478,2мен сум , 2023 елга 1534,3 мең сум күләмендә, 2024 елга 1593,4 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен раслау

2. 2022 елда Ләке авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә кирәк.

**6 Статья**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:

1) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр 2022 елга -2359,9 мең сум, 2023 елга-2430,9 мең сум, 2024 елга- 2502,0мең сум.;

2) хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр 2022 елга -103,80 мең сум, 2023 елга-107,3 мең сум, 2024 елга-111,2 мең сум.

**7 Статья**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**8 Статья**

2022нче елның 1 нче гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге исеменнән 2022 нчы елда бу муниципаль контрактларның шартлары нигезендә Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның Ләке авыл җирлеге исеменнән төзелгән, файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджеты акчасы калдыклары 2022 нче елның 1 нче гыйнварына, 2022нче елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**9 Статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

**10 Статья**

Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN .RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

**11 Статья**

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**12 Статья**

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Ләке авыл җирлеге
Советы рәисе Л.И.Шәрипова